## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“19” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 26 ноябрендә “Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту ( үлән чабу);

- Комыргуҗа авылында территорияне чистарту үлән чабу(эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылында агач кисү өчен бензопила сатып алу;
- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы урамнарын кардан чистарту (эш һәм хезмәт өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»
мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 212 (икейөз унике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 126 (йөз егерме алты) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен халык җыенында катнашучы 126 (йөз егерме алты) кеше тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту ( үлән чабу);

- Комыргуҗа авылында территорияне чистарту үлән чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылында агач кисү өчен бензопила сатып алу;
- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы урамнарын кардан чистарту (эш һәм хезмәт өчен түләү).

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000733